АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2017 елның 24 июле № 15 нче номер

**Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгында
гражданнар хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын
алыштыруга дәгъва итә торган гражданнары,
һәм Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгында
дәүләт гражданнар хезмәткәрләре
һәркемгә ачык мәгълүматны
һәм үзләрен үзбилгели торган
хәбәрләрне кабул итү һәм "Интернет"
мәгълүмат-телекоммуникация челтәре
сайтларындагы сәхифәләрдәге
яки сайтлардагы адресларда
урнашкан хәбәрләрне тикшерү
һәм эшкәртү тәртибен раслау**

2004 елның 27 июлендә 79-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең дәүләт хезмәте турында" Федераль законының 20.2 маддәсенә, 2003 елның 16 гыйнварында 3-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасының дәүләт хезмәте" Татарстан Республикасы Законының 17.2 маддәсенә таянып,

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында гражданнар хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын алыштыруга дәгъва итә торган гражданнары, һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт гражданнар хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны һәм үзләрен үзбилгели торган хәбәрләрне кабул итү һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтларындагы сәхифәләрдәге яки сайтлардагы адресларда урнашкан хәбәрләрне тикшерү һәм эшкәртү тәртибен раслау Тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз вәкаләтемдә калдырам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

**Татарстан Республикасы**
**Инвестицион үсеш агентлыгы**
**боерыгы белән**
**24.07.2017 елда**
**15нче номер астында**
**расланды**

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында гражданнар хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын алыштыруга дәгъва итә торган гражданнары, һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт гражданнар хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны һәм үзләрен үзбилгели торган хәбәрләрне кабул итү һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтларындагы сәхифәләрдәге яки сайтлардагы адресларда урнашкан хәбәрләрне тикшерү һәм эшкәртү

ТӘРТИБЕ

## I. Гомуми кагыйдәләр

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында гражданнар хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын алыштыруга дәгъва итә торган гражданнары, һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны һәм үзләрен үзбилгели торган хәбәрләрне кабул итү һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтларындагы сәхифәләрдәге яки сайтлардагы адресларда урнашкан хәбәрләрне тикшерү һәм эшкәртү тәртибе (алга таба – Тәртип) билгели:

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында гражданнар хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын алыштыруга дәгъва итә торган гражданнары (алга таба – гражданин), һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре, Агентлык) һәркемгә ачык мәгълүматны һәм үзләрен үзбилгели торган хәбәрләрне кабул итү тәртибе һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтларындагы сәхифәләрдәге яки сайтлардагы адресларда урнашкан хәбәрләрне тикшерү һәм эшкәртү (алга таба – сайтлардагы, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат);

Сайтлардагы хәбәрләрне кабул итү һәм тикшерү тәртибе;

Сайтлардагы хәбәрләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

2. Һәркемгә ачык мәгълүматк дигәндә, 2006 елның 27 июлендә 149-ФЗ номеры белән кабул ителгән “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау” Федераль законының 1 өлеше, 7 маддәсе буенча бервүгә дә карау тыелмаган, ягъни һәркемгә ачык булган хәбәрләр, һәм башка төр мәгълүмат күздә тотыла. Шул ук вакытта, әлеге мәгълүматның тыелмаган булуы аны ала торган кеше санының чикләнмәгән булуын, һәм бу мәгълүматны алучыларның урнаштырылган мәгълүматны, граждан хезмәткәре һәм гражданин белән килешүдән тыш, үз күзаллаулары буенча файдалана алуын да исәптә тота.

3. Граждан хезмәткәре һәм гражданинны үзбилгели торган мәгълүматлар сыйфатында түбәндәгеләр карала ала: аларның фамилиясе, исеме, отчествосы, фотографиясе, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турындагы мәгълүматны җыю һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турындагы мәгълүматны тәкъдим итәләр:
гражданин – Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенә урнашканда (алга таба – гражданлык хезмәте) – гражданлык хезмәтенә урнашуга кадәр 3 календарь елны исәпкә алып;
граждан хезмәткәре – хисаптагы елдан соңгы елның 1 апреленнән дә калмыйча, хисаптагы календарь елын үз эченә алып.
5. Сайтлар турындагы мәгълүматны гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан билгеләнгән форма (алга таба – Форма) буенча тәкъдим итәләр.
6. Һәркемгә ачык булган мәгълүмат, граждан хезмәткәре тарафыннан хезмәт вазыйфаларын башкарганда урнаштырылган булса, Формада чагылмый.
7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яисә гражданин тарафыннан Сайттагы мәгълүматны тикшерү өчен җаваплы итеп (алга таба – җаваплы зат) Агентлык җитәкчесе билгеләгән юридик затка тапшырыла.
8. Җаваплы зат Форманың ничек тутырылган булуын, “Интернет” челтәрендә кулланылган һәм анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, мәгълүматларны, әлеге Тәртипкә беркетелгән Кушымтага бәйле рәвештә, Форма алынган көнне журналга терки.
9. Тутырылып бетерелмәгән рәвештә тапшырылган Форма кабул ителми.
10. Гражданин тәкъдим иткән Формада дөрес булмаган мәгълүматлар табылса, җаваплы зат аның билгеле вазыйфага урнашуына каршы булган җавапны кичекмәстән граждан хезмәтенә хәбәр итә.
11. Сайтлар турындагы хәбәрләр җаваплы зат тарафыннан граждан хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәтендәге кадрлар составының бердәм мәгълүмати системасы”ндагы шәхси карточкаларына теркәлә.
12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданиннар тәкъдим иткән Формалар юридик бүлектә 5 ел дәвамында саклана, аннан соң, Агентлыкның Шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре билгеләве тәртибе буенча, юк ителә.

## III. Сайтлардагы хәбәрләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Граждан хезмәткәрләре тәкъдим иткән сайтларда урнаштырылган хәбәрләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Агентлык җитәкчесе (Агентлыкта җитәкче вазыйфаларын башкаручы зат – алга таба Җитәкче) боерыгы буенча башкарыла.

14. Тикшерү өчен нигез булып хат рәвешендә тәкъдим ителгән түбәндәгеләрнең мәгълүматлары тора:

хокук саклау органнары, башка төр дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм хезмәттәге башка затлар;

сәяси партияләрнең даими хезмәттәге җитәкче органнары һәм сәяси партия булмаган гомумроссия, регионара, регион иҗтимагый оешмаларының законы;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат граждан хезмәткәрен аның мәсьәләсендә тикшерү эше башланганлыгын тикшерү эшен уздыру буенча боерык кабул ителгәннән соң 2 эш көне дәвамында хат белән кисәтергә тиеш.

16. Граждан хезмәткәре тәкъдим иткән сайтлар турындагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү җаваплы зат тарафыннан “Интернет” челтәрендәге һәркемгә ачык мәгълүматны эзләү һәм соралган мәгълүмат турындагы электрон нөхсәләрне (скриншотлар) булдыру юлы белән башкарыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү эшләренең нәтиҗәләре буенча хат рәвешендә аңлатмалар бирә ала, шулай ук – өстәмә мәгълүматлар да.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатамалар тикшерү эшенең материалларына беркетелә.

19. Тикшерү материаллары һәм эш барышында тупланган мәгълүмат министрга боерык игълан ителгәннән һәм тикшерү уздырылганнан соң 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт аралыгында тапшырыла.

20. Тикшерү эше нәтиҗәләре буенча 5 көн аралыгында җитәкче карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чарасы кабул итүгә нигез булмавы турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чарасы кабул итү турында;

материалларны, аларда хокук бозу, җинаять, экстремистик эшчәнлеккә бәйле икәнлекне белдерүче билгеләр булуына шик туган очракта, шуның белән шөгыльләнүче махсус дәүләт органнарына юнәлтү турында.

21. Җитәкче кабул иткән карар турында җаваплы зат аның мәсьәләсендә тикшерү эше алып барылган граждан хезмәткәренә хат ярдәмендә 2 эш көне дәвамында хәбәр итә.

22. Җитәкченең хат рәвешендә тәкъдим ителгән ризалыгы буенча сайтлар турындагы мәгълүмат аның мәсьәләсендә тикшерү эше кузгатылган граждан хезмәткәренә һәм бер үк вакытта Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм шәхси мәгълүматларны саклау турындагы закончалыгы буенча тикшерү уздыруга нигез булган гамәлдәге сәяси партияләрнең гомумроссия, регионара һәм региондагы сәяси партия булмаган иҗтимагый оешмаларының җитәкче органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, мәгълүмат белән ярдәм иткән гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр ителергә мөмкин.

23. Тикшерү материаллары Агентлыкның юридик бүлегендә эш тәмаланганнан соң 3 ел дәвамында саклана, аннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турындагы мәгълүматны тәкъдим итмәү очрагында каралган җаваплылык

1. Сайтлар турында мәгълүмат тәкъдим итмәгән очракта гражданин гражданлык хезмәтенә кабул ителә алмый, ә граждан хезмәткәре исә алга таба гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын башкара алмый.

2. Граждан хезмәткәре тарафыннан  сайтлар турында мәгълүмат тәкъдим итмәү аны гражданлык хезмәтеннән азат итүгә нигез була ала торган хокук бозу очрагы буларак кабул ителә.

Татарстан Республикасы
Инвестиция үсеше агентлыгы
боерыгы белән
24.07.2017 елда
15нче номер астында
расланды

Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгында гражданнар хезмәтенең
дәүләт вазыйфаларын алыштыруга дәгъва итә торган гражданнарының,
һәм Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгында дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең
һәркемгә ачык мәгълүматны һәм үзләрен үзбилгели торган хәбәрләрне кабул итү
һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтларындагы
сәхифәләрдәге яки сайтлардагы адресларда урнашкан хәбәрләрне тикшерү һәм эшкәртү буенча
хисап алып барыла торган

ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Тәкъдим ителү датасы/ Форманың кабул ителү датасы | Форманы тәкъдим итүченең ФИОсы | Форманы тәкъдим итүченең вазыйфасы (гражданин дәгъва итә торган вазыйфа) | Форманы тәкъдим итүченең имзасы (яки тәкъдим кергән №, әгәр ул почта хезмәте аша тәкъдим ителә икән) | Форманы кабул итүче затның ФИОсы | Форманы кабул иткән затның имзасы | Тикшерү буенча мәгълүмат (боерыкнң реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |